ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.12.2021 ел №219

2022 елга Баулы муниципаль районы
халкы өчен торак-коммуналь
хезмәтләргә тарифлар турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы 2022 елга Баулы муниципаль районы халкы өчен торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны расларга:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары алучылар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак фондын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен (1 нче кушымта);

- муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар алучылар өчен торак урыннан файдалануга төп ставка (наемга база ставкасы) (2 нче кушымта);

2. Торак урыныннан файдалануга база ставкасы (наемга алуның төп ставкасы) муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар алучылар өчен торак яллаган өчен гражданнарның торак хакы күләмен билгеләү методикасы буенча исәпләнә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның 13 декабрендәге
219 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН
1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары алучылар һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак фондын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләме

| № п/п | Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2022 елның 1 гыйнварыннан | 2022 елның 1 июленнән |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 2,98 | 2,98 |
| 2. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м.в | 1,34 | 1,37 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м.в | 2,73 | 2,78 |
| 4. | Торак биналарны ремонтлау һәм йорт тирәсен төзекләндерү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м.в | 3,60 | 3,67 |
| 5. | Инженерлык челтәрләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м.в | 6,73 | 6,76 |
| 6. | Муниципаль торак фондында сыек калдыкларны чыгару | Аена бер кешедән | 29,6 | 29,6 |
| 7. | Йорт эчендәге газ җиһазларын техник хезмәт күрсәтү һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,20 | 0,20 |
| 8. | Йорт эчендәге электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм карап тору | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 1,29 | 1,31 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 9. | Дератизация (дезинфекция) | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 0,15 | 0,15 |

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының

2021 елның 13 декабрендәге
219 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН
2 нче кушымта

Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар алучылар өчен торак урыннан файдалануга төп ставка (наемга база ставкасы)

| Түләү атамасы | Хезмәтне үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен (сумнарда) база ставкасы |
|---|---|---|
| Наемга база ставкасы | аена торак урынның гомуми мәйданы кв.м. | 6,11 |